**/Безнең уңышлар/**



## Ләйсән – Республика призеры һәм район конференциясендә җиңүче

10нчы февраль көнне Казан шәһәренең “Дуслык” сәламәтләндерү үзәгендә ***татар теле буенча Республикакүләм олимпиада*** булып узды. Безнең мәктәпнең VIII сыйныф укучысы **Закирова Ләйсән Рамил кызы**, әлеге ярышта катнашып, призер исеменә лаек булды (Остазы – татар теле укытучысы **Фәнүзә апа Гафиятуллина**). Ләйсәнне мәктәп өчен, районыбыз өчен китергән уңышы белән котлыйбыз! Тырышлыгы, алдына куйган максатын җиренә җиткереп башкарганы өчен рәхмәт белдерәбез.

---

20 февральдә Аксубайның 2нче мәктәбендә өлкән сыйныф укучылары арасында **"Интеллект. Сәламәтлек. Әхлак"** дип аталган экологик конференция уздырылды. Район мәктәпләреннән килгән укучылар фәнни эшләр тәкъдим иттеләр. Ләйсән үзенең остазы белән әзерләгән "Чәчү алдыннан орлыкларның үсүенә йогынты ясаучы эшкәртүнең оптималь ысуллары" дип аталган эш белән чыгыш ясады. Алар район буенча I урынны яуладылар. Ләйсәнгә һәм фәнни җитәкчесе булган **Туктамышев Рифкать абыйга** зур рәхмәтебезне белдерәбез.

---




25 февраль көнне Аксубайның В.Г.Тимирясов исемендәге 1нче мәктәбендә ***Туган телләр көненә*** багышланган чара булып узды. Анда Аксубай районының төрле мәктәпләреннән һәм бакчаларыннан балалар катнашты. Укучыларыбызның таланты һәм осталыгы конкурста күренми калмады. “Вокал” номинациясендә V сыйныф укучысы **Закиров Инсаф** һәм VII сыйныфтан **Донсков Артур** җиңүче исеменә лаек булдылар. “Сәнгатьле сүз” номинациясендә IX сыйныф укучысы **Вәлиев Ибраһим** лаеклы I урынны алды.

Балалар бакчасына йөрүче, нәни сүз остабыз **Сафиуллин Ислам**, шулай ук “Сәнгатьле сүз” номинациясендә җиңүче исеменә лаек булды. Балаларны һәм аларның остазларын җиңүләре белән котлыйбыз!

***Вакыйгалар тезмәсен редколлегия әгъзалары әзерләде***

**/Безгә кунак килде/**

## Батырлык дәресе



Ватанны саклаучылар көне уңаеннан мәктәпкә «Ватанга хезмәт итәм» берләшмәсе ветераннары катнашында батырлык дәресе узды. Әлеге оешмага төрле гаскәрләрдә хезмәт иткән ветераннар тупланган. Чик сакчылары берлеге вәкилләре Бобов Алексей, Петрянкин Леонид Григорьевич, ракета гаскәрләре вәкиле Гыйниятуллин Шамил Гомәр улы хәрби хезмәттә булган төрле хәлләр белән уртаклаштылар. Төрле гаскәрләрнең тарихи тамырлары, хәрби хезмәтнең торышы турында сөйләделәр. Дәрес ахырында кунаклар Ватанны саклауның һәрвакыт җаваплы, авыр һәм мактаулы бурычларның берсе булуын билгеләп үттеләр. Әлеге дәрес укучыларның йөрәкләрендә чын батырлык һәм Ватанга тугрылык үрнәге булып калыр дип ышанып калабыз.

***Гөлшат Закирова, рус теле һәм әдәбияты укытучысы***

**/Безнең спорт/**



Мәктәбебезнең яшь көрәшчеләре 18 февраль көнне Базарлы Матакта уздырылган атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, «Татмелиорация» оешмасының генераль директоры Залаков Әнвәр Мәхмүт улы истәлегенә багышланган турнирда катнаштылар һәм югары нәтиҗәләр күрсәттеләр. Үз авырлыкларында **Хәбибрахманов Абдулла** – I, **Сәгъдиев Рәмзис** – II, **Закиров Инсаф, Камалов Илнур, Җамаледнинов Зөлфәт** – III урыннарны алуга ирештеләр. Шулай ук егетләребезнең күрсәткече район командасына да шактый баллар өстәде һәм гомуми нәтиҗә буенча Аксубай командасы 3нче урынны алды. Егетләр, без сезнең белән горурланабыз. Көрәшчеләргә һәм аларның остазы **Камалов Ильһам Илгизәр улына** рәхмәтләребезне белдерәбез.

**/Котлыйбыз!/**

Февраль аенда туган көннәрен билгеләп үтүче дусларыбыз – V сыйныфтан **Камалов Илнурны**, VII сыйныфтан **Донсков Артур** белән **Хәбибрахманов Абдулланы**, IX сыйныфтан **Хасанов Стасны** чын күңелдән котлыйбыз. Сәламәтлек, тырышып укуларын, чын ир-егетләр булуларын теләп калабыз.

Рус теле әдәбияты укытучысы **Закирова Гөлшат апаны** да гомер бәйрәме белән котлап, исәнлек-саулык, гаилә иминлеге, озын гомер, эшендә уңышлар телибез!

**Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе**
**Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина**
**Редколлегия әгъзалары – Асия Нурматова, Кәүсәр Насыйрова, Ләйсән Закирова, Настя Сафеева.**

# Мәктәп хәбәрчесе

**№2**
**(№73)**
**февраль 2026 ел**

***Түбән Майна урта мәктәбе гәзите***

**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**

**/ Мөхәррир минбәре/**

## Кием әдәпләре



Кием – ул безнең икенче йөзебез. Ул безне салкыннан, эсседән саклый, күркәмлек өсти, үзебезне уңайлы хис итәргә ярдәм итә. Шуңа күрә без киемнәребезне кадерләп, саклап торырга тиешбез. Кием саклау әдәбе – беркемгә дә кыенлык китерми торган гади кагыйдәләр җыелмасын үтәүдән гыйбарәт.

Кием – ул акчага алынган әйбер. Аны кадерләп саклау, вакытында ремонтлау, дөрес юу һәм саклау – киемнәрнең гомерен озайту мөмкинлеге бирә. Бу, үз чиратында, яңа кием алырга китә торган чыгымнарны киметә. Ләкин мәктәптә ничә еллар эшләү дәверендә укучыларның киемнәренә карата булган игътибарсызлыкны күзәтәбез. Әти-әни баланы яңа уку елына затлы, кыйммәтле киемнәр белән озата. Спорт киемеме, яисә мәктәп формасы булсынмы, ул бераздан иясез киемгә әйләнә. Гомуми җыелышларда ул “артык” киемнәрне күрсәтәбез, чөнки аның гардеробта аунап йөргәненә аптырыйбыз. Әмма өр-яңа булган киемнәрнең хуҗалары табылмый. Ел саен, җәйге каникулга китәр алдыннан, мәктәптә әллә ничә спорт киеме, мәктәп формалары, аяк киемнәре кала. Без инде аларны еллап саклыйбыз, тик ияләрен генә таба алмыйбыз. Ә бит мәктәбебездә йөзләгән укучы да юк.

Әти-әни баласына бернәчә кием алмыйдыр дип беләбез. Киемгә карата кадерсезлек, бәлки, мәктәп формасы белән йөрергә теләмәү сәбәпле барлыкка киләдер. Бу хәлне, әти-әниләр, сез дә игътибарга алсагыз иде. Киемне саклау әллә нинди зур хезмәт сорамый бит инде. Вакытында салып, төреп куярга гына кирәк тә, үз шкафларында гына торса, үзләре үк таба алырлар иде. Балаларның шәхси шкафлары бакча төркемендә генә түгел, мәктәптә дә бар. Бу мөмкинлек бала кечкенәдән үк үз киемен кайгырту һәм тиешле урынына куярга өйрәнү өчен булдырылган. Һәр нәрсәне үз урынына кую киемгә генә түгел, башка шәхси әйберләргә карата да сакчыллык тәрбияләү чарасы булып тора.

Киемне кадерләп тоту – исраф дигән гөнаһтан саклану да бит әле. Исраф итмәү – беренчедән, әйләнә-тирә мохитыбызны саклауга өлеш кертү булса, икенчедән, малыбызны бәрәкәтле итә. Булган малны әрәм итү, тиешенчә файдаланмау һәм саклап тотмау – тәрбиясезлекнең ачык билгеләре. Мода артыннан кумыйча, булганның кадерен белеп яшәргә өйрәнү – мул тормышлы киләчәкнең нигезе. Балаларны киемнәрен кадерләп сакларга күндерү – аларга шул әйберләрне алып биргән әти-әниләрнең хезмәтен хөрмәт итәргә өйрәтү дә булып тора.

Халыкта киеменә карап каршы алсалар, акылыңа карап озатырлар, дигән әйтем дә бар. Киемне нинди җирдә булуыңа һәм нинди гамәл башкаруыңа карап сайлый белү дә кирәк. Мәсәлән, мәктәп формасы укучыга җаваплылык, эшлеклелек һәм җитдилек өсти. Кунакка барганда һәм халык арасына йорт эшләрен башкара торган кием белән чыкмыйлар. Укырга һәм эшкә су коенырга барган кебек йөреп булмый. Театрга да спорт киеменнән килмиләр. Шуңа да карамастан, безнең укучылар арасында, спорт киемен таба алмаулары сәбәпле, физкультура дәресенә мәктәп формасыннан чыгуларын еш күрергә туры килә.

Киемне кадерләп тоту – ул безнең рухи байлыгыбызны, әхлаклылыгыбызны күрсәтә. Бу гади, ләкин мөһим әдәпне һәрберебез үзендә тәрбияләргә тиеш. Булганның кадерен белергә өйрәнә алсак иде. Барлыклы, мул заманда яшәп, бәрәкәтне да онытмасак иде.

***Фәнүзә Гафиятуллина, баш мөхәррир***

## Ватанны саклаучылар көне белән!



***Хөрмәтле ир-егетләребез!***

***Сезне чын күңелдән Ватанны саклаучылар көне белән котлыйбыз. Ватан – киң төшенчә: анда гаилә дә, туган як та, укыган мәктәбең дә, туган ил дә керә. Ватанны саклау – изге бурыч. Аны саклауга илең өчен файда китерерлек белем туплау да, яратып башкарган эшең дә, гаиләң өчен терәк булу да керә. Алдыгызга куелган зур йөкләмәләрне утәрлек көчкә, һәм заман белән бергә атларлык белемнәргә ия булсагыз иде. Үзегездә чын ир-егетләргә тиешле ныклы ихтыяр көче, максатчанлык, җиңүгә омтылыш тәрбияләгез! Сезнең уңганлык белән гаилә бара, сезнең көч белән зур йортлар төзелә, сезнең ныклык һәм акыл белән илләр идарә ителә. Сезгә, укучы егетләребез, киләчәк тормышыгызда ныклы гаилә терәге, хөрмәтле әти, кирәкле хезмәткәр була алуыгызны телибез.***

***“Мәктәп хәбәрчесе” редколлегиясе***

*/Мәктәп тормышы/*

## *Февраль аенда булып үткән дәрестән тыш чаралар*



Кышын кошлар безнең ярдәмгә мохтаҗ. Шул сәбәпле, ел саен февральнең беренче атнасында башлангыч сыйныф укучылары **"Кышын кошларны ашатыйк"** акциясе үткәрәләр. Акциянең максаты – кошларга карата кайгыртучан мөнәсәбәт тәрбияләү, аларга кышкы авыр шартларда ярдәм итү. Укучылар сыйныф җитәкчеләре белән җимлекләр ясадылар, аларны агачларга элделәр, җимнәр салдылар.

---

Безнең мәктәптә 10нчы февральдә **Татарстан Республикасы Дәүләт гербы көне** билгеләп үтелде. Герб – ул флаг һәм гимн кебек, дәүләтнең төп символларыннан. Гербләр буенча илне башка дәүләтләрдән аерырга мөмкин. Тәрбия буенча директор киңәшчесе Гөлфия апа башлангыч сыйныф укучылары белән интеллектуаль әңгәмә үткәрде. Балалар Дәүләт символикасы турында сөйләделәр. Аннары яшь укучыларга өй эше бирелде: үз сыйныфларының гербын булдыру. Югары сыйныф укучылары символика турында белемнәрен тарих дәресләрендә ныгыттылар.

---



18нче февраль көнне безнең мәктәп укучылары **"Африка"** фильмын карадылар. Вакыйгалар кыш көне, Ленинград блокадасының иң авыр чорында бара. Тар-мар ителгәннән соң авылда өч бала һәм аларның әниләре генә кала. Көннәрдән бер көнне малайлар үзләре генә юлга чыга, чөнки аларның әниләре урманда азык эзләрлек сәламәтлеге булмый. Алар сугыш үткән урында табылган гаиләне һәм этне коткаралар. Бу фильм балаларны батырлыкка, кешелеклелеккә, могҗизаларга ышанырга өйрәтә.

---



«Сәяхәтче Бөркет» төбәк проекты кысаларында директор киңәшчесе Әхмәтҗанова Гөлфия апа тарафыннан **«Әни өчен Открытка – Оренбургтан тылсымлы пәрәвез»** дип аталган иҗат эше үткәрелде. Балалар Оренбург өлкәсенең уникаль мирасы белән таныштылар, видеофильм карадылар. Караганнан соң алар Оренбург кәҗәләренең мамыгын ничек эшкәртүләрен белделәр. Шулай ук укучылар Оренбург мамык яулыгының төрләрен һәм традицион бизәкләрен өйрәнгәннәр, ә аннары үз орнаментларын уйлап чыгардылар. Ахырда һәркем атаклы Оренбург яулыгы формасында һәм стилистикасында открытка төзеделәр.

---

Мәктәптәге һәр дәрестән тыш чара – ял итү, аралашу һәм киләсе дәрескә әзерләнү вакыты ул. Аны үткәрүнең иң яхшы ысулы – актив уеннарны тыныч дәресләр белән чиратлаштыру. Безнең мәктәп укучылары тәнәфес вакытында физик культура укытучысы Туктамышев Рифкать абый белән шашка һәм шахмат кебек өстәл уеннары белән шөгыльләнәләр, шулай ук кул көрәштерү ярышларында катнашалар.

---



18нче февраль көнне «Бөркетләр сәяхәте» проекты кысаларында балалар сыйныф җитәкчесе Рузилә апа белән Пенза өлкәсенә – уникаль Пенза керамикасы дөньясына юл тоттылар. Алар Абашев уенчыгы, борынгы сакчылар, болан һәм сарык мөгезләреннән ясалган сыбызгылар белән таныштылар. Соколка авылында ясала торган Соколка керамикасы турында файдалы мәгълүмат белдек. Пенза осталары кагыйдәләрен үтәп, чүлмәкләрне мөстәкыйль бизәделәр. Пенза керамикасы – ул балчыктан эшләнгән әйберләр генә түгел, ә халык традицияләренең чын тарихы. Сәяхәттә катнашучы һәркем ата-баба мирасының матурлыгын саклап һәм тапшырып, үзен халык остасы итеп тойды. Хезмәтегез һәм осталыгыгыз өчен рәхмәт сезгә!

---

-

Безнең укучылар барысын да булдыра! Технология дәресендә башлангыч сыйныф укучылары тәмле бутербродлар ясарга өйрәнделәр. Дәрес файдалы, күңелле һәм тәмле үтте.

17 нче февраль көнне укучыларыбыз Махсус хәрби операциядә катнашучы сугышчыларга хатлар яздылар. Әлегә хатларда балалар үзләренең рәхмәтләрен белдерделәр һәм егетләрнең исән- сау әйләнеп кайтуларын теләделәр. Теләкләребез адресатларына барып җитәр диган өметтә калабыз.

***Вакыйгалар тезмәсен редколлегия әгъзалары әзерләде***

---

## *Муса Җәлилне искә алдык*

*/ Безнең бәйрәмнәр /*



2026 елның 15нче февралендә татар шагыйре Советлар Союзы герое Муса Җәлилнең туууына 120 ел тулды. Аның тормышы һәрберебезгә таныш һәм якын, ә иҗаты – кабатланмас батырлык символы.

Әле ел башында ук безнең балалар бакчасында Муса Җәлилгә багышлап төрле чаралар үткәрү планлаштырылды:

- сөйләм телен үстерү шөгыльләндә – Җәлилнең балачагын, укыгандагы уңышларын өйрәнү;
- әңгәмәләрдә, җыр-шигырьләрен ятлаганда аның батырлыгын, туган иленә мәхәббәтен, тугрылыгын күрсәтү;
- рәсем шөгыльләрендә ятлаган шигырьләргә иллюстрацияләр ясау һ.б.

Әлеге чараларның максаты – сабыйларны бөек татар шагыйре иҗаты белән ныклап таныштыру; аның балачагы турындагы истәлекләрне өйрәнеп, аңа охшарга тырышу теләге тудыру; аның тырышлыгын, зирәк акылын, батырлыгын күреп соклану, горурлану хисләре уяту.

Чыннан да, Муса Җәлилнең иҗатына сокланмаган кеше юктыр. Аның шигырьләре бик оста һәм шома итеп язылган. Балалар хәтеренә җиңел кереп кала һәм телдә үзеннән-үзе әйтелеп тора.



Җәлилгә багышланган чараларны йомгаклау максатыннан 16нчы февраль көнне балалар бакчасында "Татар халкының бөек улы, герой шагыйрь Муса Җәлил"дип исемләнгән кечкенә бәйрәм үткәрдек. Бәйрәм барышында Җәлилнең тормыш юлын, иҗатын кабатладык, шигырьләрен күңелдә ныгыттык. Китапханәче Рузилә апалары алып кергән китапларны карап, балаларның фикерләрен тыңладык.

Бу чарада иң истәлекле, шатлыклы вакыйга – башлангыч сыйныф укучыларының кунакка керүе булды. Әле генә бакчадан чыгып киткән дусларын безнең нәниләр бик шатланып каршы алды. Алар инде зур үскәннәр, үзләрен чын укучыларча, акыллы, җитди итеп тота беләләр. Һәммәсе дә үзләре өйрәнгән Муса Җәлил шигырьләрен сөйләде. Башлангыч укучылары бергәләшеп шагыйрьнең көйгә салынган җырларын җырладылар. Бакчада өйрәнгән хәрәкәтле уеннарны искә төшерделәр. Ихлас аралашудан күңелләр шатланды, вакытның узганы сизелми дә калды.

Балаларыбыз каһарман шагыйрь Муса Җәлил турындагы истәлекләрне күңелләрендә мәңге саклар дип ышанасы килә.

***Гөлүсә Насыйрова, балалар бакчасы тәрбиячесе***

---

## *Батыр булып үсик!*

*/Безнең бәйрәмнәр/*



Бер бәйрәм бар февральда
Кадерле ул һәркемгә.
Аны иң зур бәйрәм дип
Мөмкин хәтта әйтергә.

Ул тынычлык бәйрәме
Аны һәр кеше белә.
Ватанны саклаучылар
Бәйрәме дип йөртелә...

Ватанны саклаучылар көне уңаеннан 20 нче февраль көнне мәктәптә башлангыч сыйныф укучылары белән берлектә Ватанны саклаучылар көненә багышланган бәйрәм үткәрелде. Бу чара ярыш формасында оештырылган иде. Бәйгедә "Кызыл йолдыз" һәм "Юлдаш" үзара командалары көч сынаштылар.

Беренче сәламләшү булды һәм командалар үз капитаннарын сайладылар. Аннан соң укучылар үзләренең җитезлекләрен сынадылар: вакытка күзләрен бәйләп тар сукмактан йөрү, солдат киемнәрен кию, кара-каршы туп бәрешү, якорь күтәрү, яраланган солдатны коткару, беренче ярдәм күрсәтү кебек уеннар оештырылды. Шулай ук тел байлыгын, тапкырлыкларын, зирәклекләрен тикшерү өчен төрле бәйгеләр үткәрелде.



Укучылар үзләренең кыю, батыр һәм тапкыр булганнарын исбатладылар. Ахырдан җиңүчеләребезне бүләкләдек. Бәйрәм күңелле һәм мавыктыргыч үтте.

Февраль ае дәвамында герой шагыйрь Муса Җәлил 120 еллыгы уңаеннан да күптөрле ачык чаралар үткәрдек. Бу дәресләрдә шагыйрьнең бала чагына, Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыкларына, иҗатына кызыксыну уятырга тырыштык.

***Сирин Камалова, башлангыч сыйныфлар укытучысы***